ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.03.2020 Олы Кайбыч ав. № 122

Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Җир кодексына һәм «Аквакультура (балык үрчетү) турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 27 декабрендәге 502-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ЧЫГАРА:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 29 маендагы 256 номерлы карары белән расланган Торглар үткәрмичә генә арендага муниципаль милектәге җир кишәрлеген бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (10 нчы кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 39 пунктча өстәргә:

«дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге балык үрчетү кишәрлегеннән файдалану шартнамәсе (алга таба - балык үрчетү урыныннан файдалану шартнамәсе) нигезендә товар аквакультурасын (товар балык үрчетүен) гамәлгә ашыручы затка күрсәтелгән максатлар өчен.».

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 29 маендагы 256 номерлы карары белән расланган Муниципаль милектәге өске су объектын яисә аның өлешен файдалануга бирү турында карар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (24 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.4.1. пунктының 2.5 пунктының 4 пунктчасында «күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокуклар» сүзләрен «күчемсез мөлкәткә» сүзләренә алмаштырырга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары Э.Х. Заһидуллинага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров